Китапхана
Национальная
библиотека
Республики Татарстан

# Хәзинәле гомер

Күренекле әдип Гариф Ахуновның
тууына 100 ел тулуга багышланган
методик-библиографик ярдәмлек

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2024

Татарстан Республикасы
Милли китапханәсе

# ХӘЗИНӘЛЕ ГОМЕР

Күренекле әдип Гариф Ахуновның
тууына 100 ел тулуга
багышланган методик-библиографик ярдәмлек

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2024

**УДК 929:821.512.145 Ахунов Г.**
**ББК 83.3(2=632.3)6-8 Ахунов Г.**
**Х 84**

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
редакция-нәшрият шурасы карары белән басыла

*Төзүчесе Р.Р. Гаязова*
*Мөхәррире И.Г. Һадиев*

**Х 84** **Хәзинәле гомер:** күренекле прозаик, драматург, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Гариф Ахуновның (Гариф Ахунҗан улы Ахунов; 1925–2000) тууына 100 ел тулуга багышланган методик-библиографик ярдәмлек / Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. Р.Р. Гаязова; мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2024. – 48 б.

Ярдәмлек Гариф Ахуновның үз әсәрләре, аның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган әдәбият белән эшләү өчен китапханәчеләргә тәкъдим ителә. Җыентыкта әдәби кичә үрнәге, фикер алышулар үткәрү өчен материаллар, китапханәчегә киңәшләр һәм әдәбият исемлекләре бирелә.

**УДК 929:821.512.145 Ахунов Г.**
**ББК 83.3(2=632.3)6-8 Ахунов Г.**

© Татарстан Республикасы
Милли китапханәсе, 2024
© «Милли китап» нәшрияты, 2024

# КЕРЕШ СҮЗ

*«Мирас калдыра алган кеше бәхетле.*
*Мирас ул – адәм баласының киләчәк буынга васыяте».*
*Гариф Ахунов.*

2025 елның 18 сентябрендә күренекле прозаик, драматург, публицист һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Гариф Ахуновның (Гариф Ахунҗан улы Ахунов; 1925–2000) тууына 100 ел тула.

Гариф Ахунов – татар халкының тарихи үсешендә тирән эз калдырган, бөтен тормышын һәм талантын халыкка хезмәт итүгә багышлаган, узган гасырның илленче елларыннан башлап тырыш һәм гаять нәтиҗәле эшчәнлек күрсәткән әдип. Гариф Ахунов – күпьяклы, киңкырлы талант иясе. Ул – әдәбиятның алгы сафында торган, заман сулышын тойган, үткен күзле, тапкыр сүзле язучы.

Әдип үз гомерендә 5 роман, 18 повесть, 1400 ләп тәнкыйть мәкаләсе язып, 55 китап чыгарган.

Гариф Ахуновның язучы буларак беренче иҗат тәҗрибәләре студентлык елларына туры килә. 1951 елда «Үсү юлы» альманахында яшь авторның «Галләм сорау бирә» исемле тәүге хикәясе басылып чыга. 1951–1957 елларда ул «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, проза бүлеге мөдире һәм журналның җаваплы сәркятибе булып эшли. Шушы елларда ул күп кенә хикәяләрен, беренче күләмле әсәре булган «Яшьлек яме» (1955) повестен иҗат итә. Ибраһим Гази, Габдрахман Әпсәләмов, Әнвәр Давыдов, Гомәр Бәширов, Шәйхи Маннур, Салих Баттал кебек танылган язучылар турында әдәби-тәнкыйть мәкаләләрен һәм иҗат портретларын бастыра.

Гариф Ахунов 1957 елдан Әлмәткә күчеп китеп, ун елдан артык нефтьчеләр арасында яши, аларның хезмәтен, тормышларын өйрәнә. Шуның нигезендә «Еллар чатында» (1959), «Хыялый Хәйрүш егетләре» (1965), «Артышлы тау буенда»

(1960) повестьларын, «Канатлар кая илтә?» (1967), «Хәзинә» (1963) һәм «Хуҗалар» (1968) әсәрләрен иҗат итә.

1963 елның мартында Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге рәсмиләштерелеп, ул оешманың беренче җаваплы җитәкчесе итеп билгеләнә (1963–1965 һәм 1967–1968 елларда эшли), ике тапкыр Әлмәт шәһәр советына депутат итеп сайлана.

Казанга кайткач, Гариф Ахунов 1968–1971 елларда Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркятибе булып хезмәт куя, 1972–1974 елларда «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, 1974–1984 елларда Язучылар берлеге идарәсе рәисе вазифаларын башкара, СССР Югары Советы депутаты итеп сайлана.

Узган гасырның җитмешенче еллар дәвамында аның бер-бер артлы «И, кадерле туган як» (1968–1970) исемле тарихи-публицистик китабы (М.Зарипов белән бергә язылган), «Чикләвек төше» (1971), «Олы юлга сәяхәт» (1974), «Ардуан батыр» (1975), «Без бит Арча яклары» (1978), «Йолдызлар калка» (1979) кебек тарихи-публицистик, әдәби, документаль һәм автобиографик китаплары нәшер ителә.

Гариф Ахунов драма әсәрләре авторы буларак та билгеле. Төрле елларда Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Әлмәт, Минзәлә татар дәүләт драма һәм комедия театрлары сәхнәләрендә аның «Чулпы жыры», «Утлар яна учакта», «Тынгысыз йөрәк» (Ф. Мостафин белән бергә язылган), «Чикләвек төше», «Ардуан батыр», «Икәүдән-икәү генә» (соавторы – Р. Ахунов) исемле пьесалары куела. Ул үзе Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестен сәхнә өчен яраклаштырып эшли.

Гариф Ахунов – тәрҗемә остасы да. Ул татар теленә В. Закруткинның «Плавучая станица» («Йөзмә станица», 1953) романын, А. Макаренконың «Педагогическая поэма»сын («Педагогик поэма», 1957), Рабиндранат Тагорның «Хикәяләр»ен (1960), М. Шолоховның мәшһүр «Тихий Дон» («Тын Дон»)

эпопеясенең икенче, дүртенче китапларын (1964, 1965), Н. Шундикның «Быстроногий Олень» («Боланнар илендә», 1977) романын, Татар дәүләт академия театры сәхнәсе өчен Н. Погодин һәм А. Островский пьесаларын тәрҗемә итте. Аның үз әсәрләренең дә күбесе русчага тәрҗемә ителгән, хикәя һәм повестьлары украин, үзбәк, кыргыз, мари, чуваш, якут һ.б. телләрдә басылып, «Хәзинә» романы казакъча һәм төрекмәнчә тәрҗемәдә нәшер ителгән.

Әдәбият өлкәсендәге казанышлары һәм иҗтимагый тормыштагы актив эшчәнлеге өчен Гариф Ахунов Хезмәт Кызыл Байрагы (1975 ел), Халыклар Дуслыгы (1981 ел) орденнары белән бүләкләнә. 1972 елда аңа «Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә, ә 1993 елда Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев Указы белән ул «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мәртәбәле исемгә лаек була. Әдип шулай ук 1998 елдан Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы дигән мактаулы исем йөртә. 1973 елда «Чикләвек төше» повесте һәм «Хәзинә» романы өчен Гариф Ахунов Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Ул 2000 елның 4 июнендә Казанда вафат була һәм туган ягы Арча зиратына җирләнә.

Гариф Ахуновның юбилей елын китапханәләрдә зурлап билгеләп үтәргә, ярдәмлектә бирелгән материаллардан, әдәбият исемлегеннән файдаланып төрле чаралар: әдәби кичәләр, әдәби батллар, тукталышлы укулар, айлыклар яки атналыклар, фикер алышулар, әңгәмәләр, интеллектуаль уеннар һ.б. үткәрергә мөмкин.

Интернет челтәрендә акцияләр уздырырга, виртуаль китап күргәзмәсе, әдипнең китапларына, ул тәрҗемә иткән әсәрләргә презентацияләр, буктрейлерлар ясап урнаштырырга мөмкин.

Чараларны оештырганда әтисе турында истәлекләре белән уртаклашу өчен Гариф Ахуновның кызын – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, шагыйрә, Сажидә Сөләйманова

һәм Максим Горький исемендәге әдәби бүләкләр иясе Наилә Ахунованы чакырырга киңәш итәбез.

Әлеге ярдәмлектә «Хәзинәле гомер» дигән әдәби кичә сценарие, «Йолдызлар сүнми» дип аталган искә алу кичәсе үткәрү өчен әдәбият исемлеге, викторина үткәрү өчен сораулар һ.б. бирелә. Аларны оештыру өчен киңәшләр дә тәкъдим ителә.

Китапханәчеләр әдипнең юбилей елын олылап уздыру өчен ярдәмлектә бирелгән материаллардан уңышлы файдаланырлар дип ышанып калабыз.

## ЙОЛДЫЗЛАР СҮНМИ

*(Гариф Ахуновны искә алу кичәсе)*

*Кичә язучының иҗатташлары, хезмәттәшләре, замандашларының истәлекләренә нигезләнеп төзелә. Күрсәтелгән чыганакларда тупланган истәлекләрне, хатларны 2 укучы чиратлашып укыйлар. Кичәгә шулай ук Фоат Галимуллинны, Наилә Ахунованы һ.б чакырырга була. Истәлекләр арасында музыкаль тәнәфесләр оештырырга киңәш итәбез.*

*Чараны башлар алдыннан, Гариф Ахуновның биографиясе белән таныштыру өчен, Татар энциклопедиясе хезмәткәрләренең видеоязмасын түбәндәге сылтама буенча:*

*https://tatarica.org/ru/razdely/kultura/literatura/personalii/ahunov-garif тыңлатырга тәкъдим итәбез.*

### Файдалану өчен әдәбият исемлеге:

1. Әхмәтҗанов М. Үзе тапкан хәзинә: [Г.Ахунов иҗаты турында] // Мирас. – 1997. – № 12. – Б. 37–42; 1998. – № 1.– Б. 45–57.

2. Галиуллин Т. Ул шәхес иде: [язучы Г.Ахунов турында] // Мәйдан. – 2015. – № 9. – Б. 78–82.

3. Гариф Ахунов: истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 240 б.

4. Гариф Ахунов: шәхес, иҗат, заман: Гариф Ахуновның тууына 90 ел тулуга багышланган республика фәнни-гамәли кон-

ференциясе материаллары (21 октябрь, 2015). – Арча, 2015. – 147 б.

5. Гариф Ахунов. Хәзинәле гомер. – Казан: Рухият, 2015. – 376 б.

6. Гариф Ахунов: [язучы турында] // Мәйдан. – 2015. – № 9. – Б. 4–6.

7. Мулланурова Р. Игелекле гомер: [язучы Г.Ахунов турында] // Мәйдан. – 2015. – № 9. – Б. 83–86.

8. Мусин Ф. Гариф Ахунов (1925–2000) // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда: Т. 6: 60–80 еллар әдәбияты. – Казан: Раннур, 2001. – Б. 141–155.

9. Надыршина Л. Гариф Ахунов (1925–2000) // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда: Т. 6: 1960–1980 еллар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – Б. 123–139.

10. Нәҗипова-Зиннәтуллина Ә.Н. Хәзинәләр тапкан әдип // Ахунов Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Хәтер, 2005. – Б. 5–16.

## ХӘЗИНӘЛЕ ГОМЕР

*(Әдәби кичә)*

*Зал бәйрәмчә бизәлә. Гариф Ахуновның портреты, китап күргәзмәсе, тормыш юлы һәм иҗатына багышланган стенд, аның турында күренекле шәхесләр сүзләре язылган плакатлар куела. Кичәгә килгән кунакларга язучының тормыш юлыннан төп вакыйгаларны тасвирлап ясалган кечкенә буклетлар таратыла.*

*Кичәнең башыннан ахырына кадәр проектор аша экранда Гариф Ахуновның иҗаты һәм тормышы белән бәйле фотосурәтләр күрсәтелә.*

*Гариф Ахунов шигыреннән өземтә языл эленә:*

*«Якты көн, сабырлык бир миңа*
*Гомеремә җитәрлек –*
*Шатлыгымнан шашынмаслык,*
*Кайгымны юк итәрлек!»*

*(Кичә башланганда экранда Гариф Ахуновның фотосы һәм «Хәзинәле гомер» дип язылган слайд күрсәтелә).*

*Залга алып баручылар чыга. (Салмак кына «Арча» җыры (татар халык көе) ишетелә).*

**1 а.б.** «Татарстанда Тукай Казан арты дип билгеләгән бер як бар. Себер тимер юлы белән Казаннан алтмыш чакрымнар киткәч, Арча булыр. Автобуска утырып, шул чама баргач, Кенәрләр, Әтнәләр булыр. Әнә шул инде ул Казан арты. Дан булып җырларга кергән Иделләре, Агыйделләре, Чулманнары да юк аның, көмеш күлләре дә күренми. Әмма урманнары бик матур, кешеләре киң күңелле. Булдыклылык, тырышлык дисәң, аларга тиң бар микән?! Нәкъ Казан артында, Арча белән Балтач арасында, тау башына менеп кунаклаган унөч кенә йортлы Кечкенә Өчиле авылы бар иде. Өч йөз ел яшәп тә унөч өйдән артмаганга, кешеләр аны «шүрәле каргаган» дип йөртәләр иде. Әнә шул Кечкенә Өчиленең урта хәлле крестьяны Ахунҗан гаиләсендә өченче бала булып мин дөньяга килгәнмен.

«Ачлык елдан соң дүрт ел үткәч, бәрәңге алганда тудың син, балам. Әтиең, син тугач, ак күлмәкләр тектерде», – ди торган иде әни. Бәрәңге алганда дигәне 1925 елның 18 сентябре булып чыкты».

**2 а.б.** Гариф Ахуновның әтисе Ахунҗан абзый, авылның беренче совет активистларыннан булып, күмәкләшү чорында ярлы крестьяннар арасында зур оештыру эшләре алып бара һәм шул эшләре өчен 1931 елда кулаклар тарафыннан үтерелә. Алты яшендә әтисез калган Гарифҗанны һәм аның өч туганын әниләре карап үстерә.

**1 а.б.** *(Алып баручы Гариф Ахуновның «Җуелмас яра» хикәясеннән өзек укый).*

«Дөньяны аңлый башлагач алган беренче ярам – әтисез калу. Әтиемне авыл кешеләре әле дә сагынып сөйлиләр. Тәбәнәк буйлы булса да, төптән нык булып үскән бик гайрәтле кеше иде, диделәр. Авылда ул беренче коммунист була, Өчиледә колхоз оештыра. Аның, урта хәлле крестьянның, коммун булып китүе Сукыр Аптул белән бәйле. Бездән өч

чакрымда Казанбаш исемле авылның «ата пролетары» Габдулла Заһидуллин, Донбасс шахталарын айкап, дөньяның кая таба барганын тоеп кайта. Минем әтине үз юлыннан әнә шул кеше алып китә. Әти председатель булып эшләгәндә, шкафтан алып, ниндидер сары кенәгә ертканымны хәтерлим. Хәтерләвемнең сәбәбе – әти минем арт чүмечкә кизәнми генә берне салды һәм мин, егылып, борынымны канаттым.

Алтынчы яшем белән барганда аны кулаклар үтерде. Өчиледә җыен-сабантуй чаклары. Бездә – өй тулы кунак. Әти, кара туры айгырны җигеп, иртүк Төрнәле авылына чапты. Мин, күрше малае Мансур белән, урамда шырпы тартмасына бал корты ябып, умарталы уйнап йөри идек, безнең йөрәк кагып чаба торган кара айгыр гөрселдәп авылга килеп керде».

**2 а.б.** Гариф Ахунов, Казанбаш авылы мәктәбендә җиде сыйныф белем алганнан соң, Арча педагогия училищесын, В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый.

Гариф Ахуновның язучы буларак беренче иҗат тәҗрибәләре студентлык елларына туры килә. Яшьтән үк рәсем сәнгатенә гашыйк егет уку елларында иҗатка тагын да ныграк тартыла, матбугатта аның беренче хикәяләре һәм әдәби тәнкыйтькә багышланган мәкаләләре басыла башлый. 1951 елда «Үсү юлы» альманахында яшь авторның «Галләм сорау бирә» исемле беренче хикәясе басылып чыга. Ул шулай ук газета-журналларда очерклары, рецензия һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән күренә башлый. Шул ук 1951 елда, университетның соңгы курсында укыган чагында, аны «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясенә әдәби хезмәткәр итеп эшкә алалар. Мондагы хезмәтен ул университетны тәмамлап чыкканнан соң да дәвам иттерә – алты ел буе анда әдәби хезмәткәр, проза бүлеге мөдире һәм журналның җаваплы сәркятибе вазифаларын башкара. Бу елларда ул күп кенә хикәяләрен, беренче күләмле әсәре булган «Яшьлек яме» (1955) повестен иҗат итә. *(Экранда «Яшьлек яме» исемле китабының тышлык сурәте күрсәтелә).* Ибраһим Гази, Габдрахман Әпсәләмов, Әнвәр Да-

выдов, Гомәр Бәширов, Шәйхи Маннур, Салих Баттал кебек танылган язучылар турында әдәби-тәнкыйть мәкаләләрен һәм иҗат портретларын бастыра.

**1 а.б.** *(Алып баручы Гариф Ахуновның «Яшьлек яме» әсәреннән өзек укый).*

«Гөлнур бер төш күрде.

Әллә каян бер хыялый тау пәйда булды. Гөлнур шул тау итәгеннән килә, имеш. Йөгерә-йөгерә, көлә-көлә килә. Хыялый тау, мең төрле нурларда балкып, күзне камаштыра... Тау итәгендә ап-ак булып шомырт чәчәк аткан, чия чәчәк аткан, каяндыр бик матур булып, моңлы булып музыка ишетелә.

Ул да түгел, алар икәү булып чыктылар. Яшь кенә егет белән җитәкләшеп киләләр. Каяндыр йөгереп Дилбәр Шаммазова, Мостафа Мәһдиев, Салават Атнабаев, Геннадий Хубльдиков килеп чыктылар. Тау башыннан киләләр, Гөлнурларга кул болгыйлар.

– Кая барасыз? – дип кычкыралар.

Гөлнур җавап бирергә тели, ләкин сүзләре нишләптер бик әкрен чыга. «Менә егерме чакрым җир килдем, соңгы өч-дүрт чакрымны узганда шушы егетне очраттым, – дип әйтергә тели ул, – сукмакларыбыз бергә кушылды», – дип әйтергә тели, ләкин әйтә алмый, егеткә карап елмая гына, егет тә елмая. Карале, егете Таһир икән бит... Таһир Юлдашев икән...

Кояш нурында тау бик каты ялтырап күзне чагылдыра башлады. Тау башыннан баручы Дилбәр әллә кая китеп юк булды. Таһир да юк булды. Гөлнур берьялгызы гына калды. Йөгерергә теләде, ләкин аяклары буйсынмады. Кинәт ул тау түбәсеннән Таһирның упкын кырыена якынлашуын күрде... Коты алынып, күзләрен ачып җибәрде. Йөрәге еш-еш тибә. Инде яктырган, стенада әкрен генә радио уйнап тора, кызлар лекциягә барырга әзерләнеп йөриләр. Урамда ап-ак булып яңа кар яуган, тәрәзәдән бөркелгән кышкы яктылык, ак кар яктысы күзләрне камаштыра. Әле генә күз алдында торган нурлы тау, үзе белән бергә елмаеп атлаган Таһир, тау башыннан кул болгаучы иптәшләре – үзенең матурлыгы, бәхетле итүе белән йөрәкне кысып китергән

шушы күренеш аның күз алдында балкып торды, моның төш кенә булуына ышанмыйча, ышанырга да теләмичә, ул тагын күзләрен йомды. Юк, бу төш кенә түгел, бу чын, аның бәхете бик якын иде инде».

**2 а.б.** 1956 елда Гариф Ахунов республиканың нефть үзәге Әлмәт шәһәренә берьеллык иҗади командировкага җибәрелә, ә 1957 елдан гаиләсе белән шунда күчеп китеп, ун елдан артык нефтьчеләр арасында яши, аларның хезмәт казанышларын һәм көндәлек тормышларын өйрәнә. Күпсанлы очерклар, публицистик мәкаләләр, хикәяләр, кечкенә повестьлар, романнар яза. *(Экранда Гариф Ахунов китапларының тышлык сурәтләре күрсәтелә).*

**1 а.б.** Татарстан төбәгендә нефть хәзинәсе табылудан татар халкының яшәешенә, көнкүрешенә килгән үзгәрешләрне, шул яңача шартларда төрле буын һәм төрле кәсеп ияләре арасында күзәтелгән катлаулы социаль һәм әхлакый мөнәсәбәтләрне реалистик буяуларда сәнгатьчә гәүдәләндергән «Хәзинә» романы әдәби җәмәгатьчелектә 1960 нчы еллар татар прозасына яңалык алып килгән, аны яңа тормыш материалы һәм яңа геройлар белән баеткан әсәр итеп бәяләнә. Тиздән роман рус теленә дә тәрҗемә ителә һәм Казан, Мәскәү нәшриятларында басылып, Татарстан нефтьчеләрен бөтенсоюз аренасына алып чыга, популярлык казана.

1977 елда бу роман буенча Свердловск (Екатеринбург) киностудиясендә шул исемдәге нәфис фильм да төшерелә, ә соңрак, 1983 елда, «Кошның да үз оясы була» дип исемләнгән инсценировка рәвешендә (авторы М.Шиһапов) Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә куела.

*(Экранда Гариф Ахуновның «Хәзинә» әсәре буенча төшерелгән нәфис фильмнан өзек күрсәтелә).*

**2 а.б.** Гариф Ахуновның Әлмәт чоры әдәби иҗат өлкәсендәге уңышлары белән генә түгел, иҗтимагый активлыгы белән дә игътибарга лаек. 1963 елның мартында Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге рәсмиләштерелеп, ул оешманың бе-

ренче җаваплы җитәкчесе буларак (1963–1965 һәм 1967–1968), Гариф Ахунов нефть төбәгендә яшәүче язучыларны иҗади коллективка туплау, яңа яшь әдәби көчләрне эзләп табу һәм тәрбияләп үстерү юнәлешендә мөһим эшләр башкара, шул чорда ике тапкыр Әлмәт шәһәр советына депутат итеп сайлана.

**1 а.б.** Татарстан әдипләренең җиденче корылтаеннан соң республика Язучылар берлегенең җаваплы сәркятибе итеп сайлануы сәбәпле, Гариф Ахунов 1968 елда Казанга кайта. 1972–1974 елларда ул «Казан утлары» журналының баш мөхәррире булып эшли. *(Экранда Гариф Ахуновның редакциядә эшләгән вакыттагы фотосурәтләре күрсәтелә).* 1974 елның май аенда узган сигезенче корылтайда исә каләмдәшләре аны Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең рәисе итеп сайлыйлар. Идарә рәисе булып Гариф Ахунов тугызынчы корылтайда да (1979) сайлана һәм бу хезмәтен 1984 елның маена кадәр дәвам иттерә. 1974–1984 елларда ул шулай ук СССР Югары Советында Татарстаннан сайланган депутат вазифаларын башкара.

**2 а.б.** 1970 нче еллар дәвамында аның бер-бер артлы «И кадерле туган як» (1968–1970) исемле тарихи-публицистик китабы (М.Зарипов белән бергә язылган), «Чикләвек төше» (1971), «Олы юлга сәяхәт» (1974), «Ардуан батыр» (1975), «Без бит Арча яклары» (1978), «Йолдызлар калка» (1979) кебек тарихи-публицистик, әдәби, документаль һәм автобиографик китаплары нәшер ителә. Гариф Ахунов 1973 елда «Чикләвек төше» повесте һәм «Хәзинә» романы өчен Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. 1978, 1986 елларда әдипнең өч кисәкле роман итеп уйланылган «Идел кызы» исемле трилогиясенең беренче ике китабы басылып чыга. Кызганычка каршы, бу трилогиянең өченче кисәге язылмыйча кала.

**1 а.б.** *(Алып баручы Гариф Ахуновның «Идел кызы» әсәреннән өзек укый).*

«...Залда ут сүнде. Караңгы зал, бер генә мәлгә кыштырдап, пышылдап алгач тынды. Партеры, балконы, бельетажы шыплап тутырылган һәм инде менә тынып калган театрда

моңлы бер көй агыла башлады. Шул моңга ияреп тамашачылар сәхнә ачылганын, саллы авыр пәрдәнең ике якка шуышып кереп җыелганын да сизми калдылар. Күз камашырдай якты, нурлы сәхнәдә Мәйсәрә җырлап килә иде. Җырга сусаган кешеләр, матурлыкка, иреккә сусаган кешеләр Мәйсәрә сылуга карап таң калдылар. Аннары Булат кайтты. Үзе белән авыл егетләрен, авыл кызларын ияртеп керде, шахтёрлар санын меңәрләп кенә санаган чит-ят җирләр турында, тирән күмер базлары турында җыр җырлады, сөйгәненә күз явыңны алырлык зәңгәр шәл бүләк итте. Алардан соң Мәйсәрәнең явыз агасы Җиһанша сәхнәдә котырынып йөрде. Ишан хәзрәт: «Алла сакласын, Алла сакласын, күкрәгеңә җен оялый күрмәсен!» – дип, Мәйсәрә тирәсендә бөтерелде. Булат белән Мәйсәрәне, аларның керсез хисләрен һәм шул хисләр алиһәсе булган зәңгәр шәлне хәтерендә саклап, халык тәнәфескә чыкты.

Театр фойесында халык бик чуар иде: чачаклы-чуклы итеп киенгән бистә мещаннары буфетка йөгерделәр; яңа экономик политика чорында кесәләрен калынайтырга өлгергән нэпманнар алдан ук өстәлләр әзерләтеп куйганнар икән, ашыкмый гына шунда барып утырдылар; фойеда зыялы театраллар белән анда-монда барырга мөмкинлекләре булмаган эшчеләр, совет учреждениесе хезмәткәрләре торып калды, дөресрәге, алар карусель кебек гел әйләнеп тордылар, бүгенге тамашадан алган хисләрен уртаклаштылар, театрга матур киләчәк юрадылар.

Солтан белән Нурия яныннан Кәрим Тинчурин узып китте. Ул кара костюмнан, галстуктан, штиблеттан иде, мәһабәт олы гәүдәсе белән сизелер-сизелмәс иелә төшеп, ягымлы елмаеп, ике яшь кешенең, хөрмәт белән сәламләүләрен алып китте. Нурия белән Солтан шагыйрь Такташны күрмәбезме дип тә хыялланганнар иде, тик бүгенгә аны күрү бәхетенә ирешә алмадылар.

Спектакльнең икенче пәрдәсе, сәхнә ачылу белән үк, халыкны үз ихтыярына буйсындырды. Тормыштагыча чын, хәтта аннан да чынрак итеп эшләнгән кара урман, җил исеп куйса, шаулый башлар кебек тоела; төрле яктан утлар белән

яктыртылганга, күңелдә әллә ниткән зур уйлар кузгата, залда утыручыларның урман белән, елга-сулар белән, сахра-кырлар белән бәйле истәлекләрен берьюлы кабыза иде – күренешкә гөрләтеп кул чаптылар.

Аннары качкыннар җыры башланды. Татар музыкасы күгенә күтәрелеп килгән яңа йолдыз – Сәйдәшнең таланты залдагыларны әсир итте, үз аһәңенә, үз ритмына буйсындырды, һәркем үзе җырлардай булып, ярсынып-дәртләнеп утырды».

**2 а.б.** Гариф Ахуновның үткән тормышы һәм хезмәт юлы – сокланырлык бай, күпкырлы. Ул үзен күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе итеп таныта. Мондый дәрәҗәгә ул искиткеч тырыш, эшчән, гадел, кешелекле сыйфатлары аркасында ирешә.

1980 нче елларның икенче яртысында һәм 1990 нчы еллар дәвамында әдип «Гомер юлы» романын, «Этләр патшасы», «Соңарган мәхәббәт» исемле кече күләмле ике повестен һәм өч кисәктән торган «Тимерханның күргән-кичергәннәре» дигән документаль әсәрен иҗат итә.

**1 а.б.** *(Алып баручы Гариф Ахуновның «Тимерханның күргән-кичергәннәре» әсәреннән өзек укый).*

«Тимерхан абый төш күреп уянды.

Төше шулхәтле дә матур, шулхәтле дә дулкынландыргыч һәм чын иде ки, Тимерхан абзый әле уянгач та, җанын тутырган ләззәттән арына алмыйча, күзләрен йомган килеш ятты. Ул белә: уяну белән күзне ачып, тәрәзәгә карадыңмы – төш онытыла. Шул хакта аңа үги әнисе кат-кат әйтә торган иде. Барлык үги аналар төсле үк, Тимерханның да үги анасы аңа назлы караш ташламады, аны үз итеп аркасыннан сөймәде, авызыннан өзеп соңгы телем ипиен бирмәде, күңелдә ул кылган игелекләр никтер торып калмаган, ә менә төш күргәннән соң тәрәзәгә карамаска кушканы гел дә хәтердә.

Әйе, төш күрде Тимерхан абзагыз. Болыннан бара, имеш. Атка атланып бара. Яз, имеш. Күзләрне камаштырырлык кояш болындагы ямь-яшел үләннәргә, аллы-гөлле чәчәкләргә көлтә-

көлтә нурын сибә. Тимерхан атланган Тимеркүк, башын чайкый-чайкый, болын чәчәкләре арасыннан бара, чапмый да, юыртмый да, атлап-атлап кына бара.

Ул да түгел, болында иңенә көянтә-чиләк күтәргән бер кыз пәйда була. Тукта-тукта бу Миңлеасия түгелме? Шул бит, шул үзе. Башына ак яулык бәйләгән, кыска җиңле зәңгәр күлмәк кигән, шундый да җиңел гәүдәле, шундый да нечкә билле. Алма бизәкле көянтә аның иңнәрен баскан, көмеш төсле ак чиләкләре мөлдерәмә суы белән атынгалап бара. Суын түкмәс өчен Миңлеасия бии-бии атлый. Һай, аның ул атлаулары! Әллә нишләтә Тимерхан дигән егетне, җаннарын айкап ала. Аның тизрәк Миңлеасияне куып җитәсе, ат өстеннән сикереп төшеп, кыз белән янәшә атлыйсы килә башлый.

Тик...Миңлеасияне куып җитәрлек түгел. Ул һаман ерагая. Тимерхан дигән үсмер егетнең атын чаптырып, аны куып җитәсе килә. Аты чапмый, аты туктый, киреләнә. Миңлеасия дигән нечкә билле, шаян табигатьле кызны – инде менә ел буе күңелен кытыклап, күкрәк турыларын сызлатып, моңсу сагышларга юлыктырган кызны югалтудан куркып, ыңгырашып җибәрә Тимерхан һәм үз тавышыннан үзе куркып, уянып китә...».

**2 а.б.** Гариф Ахуновның әдәби мирасында Казанда Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Әлмәт, Минзәлә драма театрлары сәхнәләрендә каткат куелган берничә пьесасы да бар: «Чулпы җыры», «Утлар яна учакта», «Тынгысыз йөрәк», «Чикләвек төше», «Ардуан батыр» (шул исемнәрдәге повестьлар буенча инсценировкалар), «Акчарлаклар» (Ш.Камалның шул исемдәге повесте буенча инсценировка) һ.б.

*(Гариф Ахуновның «Утлар яна учакта» әсәреннән өзек сәхнәләштерелә. Вакыйга Җәүдәт белән Гүзәлия арасында бара).*

*(Капкада язу: «Күңелең саф булса, рәхим ит!» Машина гудогы. Кулына чемодан тоткан Җәүдәт керә).*

**Җәүдәт** *(капка каршында туктап).* Шушында очрашырга сүз куештык. *(Кесәсеннән хат чыгарып карый).* «Шәһәрнең яңа капкасы булыр. Анда безнең теләкләр язылган булыр. Син шуларны укый торганчы, мин ялт итеп килеп җитәрмен. Гүзәлия». Карап карыйк, нинди теләкләр бар монда. *(Язуны укый).* «Күңелең саф булса, рәхим ит!» *(Сәгатенә карый).* Актыккы студент акчамны түләп, аэропорттан машина кудым. Киләме, юкмы? *(Чемоданына утырып уйга кала).*

*Гүзәлия керә. Җәүдәтнең башын иеп утырганын күреп, сиздермичә генә, аяк очларына гына басып атлый башлый. Җәүдәт эчке сизенү белән сикереп тора, һәм алар бер-берсенә ташланалар.*

**Гүзәлия.** Җәүдәт...

**Җәүдәт.** Гүзәлия...

**Гүзәлия.** Кайтыр көнең дә бар икән!

**Җәүдәт.** Көттеңмени?

**Гүзәлия.** Биш ел буе көтү ул чаклы озак тоелмаган иде. Соңгы биш көне... Ой, ник сөйлим соң әле мин боларны?!

**Җәүдәт.** Сөйлә син, сөйлә...

**Гүзәлия.** Сөйләр сүз күп иде... Үзеңне күргәч, онытып бетердем...

**Җәүдәт.** Гүзәлкәй!

**Гүзәлия.** Әү?

**Җәүдәт.** Йом күзеңне.

**Гүзәлия.** Ник?

**Җәүдәт.** Йом инде.

**Гүзәлия** *(аның ниятен сизеп, каушап).* Йоммыйм, йоммыйм, йоммыйм!

**Җәүдәт** *(аяк тибеп).* Йом дим!!

**Гүзәлия** *(рәхәтләнеп көлә).* Йоммыйм, йоммыйм. Сиңа карап торасым килә.

**Җәүдәт.** Сагындыңмы?

**Гүзәлия.** Син бит әле миңа дипломыңны да күрсәтмәдең!

**Җәүдәт** *(кесәсеннән дипломын алып бирә).* Мә, кара, Гүзәлкәй, сөен!

**Гүзәлия** *(карый).* Ай, нинди чибәр син монда! *(Укый.)* «Галиәхмәтов Җәүдәт Галиәхмәт улы. Туган елы – 1940». Тау инженеры! Әйдә, киттек!

**Җәүдәт.** Кая?

**Гүзәлия.** Иптәшләр янына! Алар бит сине ашкынып көтәләр. Шундый зур эшләр куптарырга торабыз!

**Җәүдәт.** Нинди эшләр?!

**Гүзәлия.** Болай гына аңлатып булмый аны. Баргач белерсең, баргач...

**Җәүдәт.** Бүген бармыйбыз...

**Гүзәлия.** Бармыйбыз?

**Җәүдәт.** Мин аларга өч көннән кайтам дип телеграмма сuктым.

**Гүзәлия.** Өч көннән?! Бу бит... алдау. Нишләдең син, Җәүдәт?

**Җәүдәт.** Алдау түгел бу, сюрприз! Аңламыйсыңмыни? Алар мине инженер булып кына кайта дип көтәләр иде. Ә мин кияү булып та кайтам!

*(Көлешәләр. Җитәкләшеп, сөенеп чыгып китәләр).*

**1 а.б.** Әдип шулай ук күпсанлы әдәби һәм истәлек язмалары, әдәби тәнкыйть мәкаләләре («Әдәби язмышлар», «Чишмәләр белән сөйләшү» исемле җыентыклар, 1970, 1985) һәм әдәби тәрҗемә китаплары белән дә укучылар арасында киң танылa. Гариф Ахунов В.Закруткинның «Плавучая станица» («Йөзмә станица», 1953) романын, А.Макаренконың «Педагогик поэма»сын (1957), Рабиндранат Тагор «Хикәяләр»ен (1960), Михаил Шолоховның «Тихий Дон» («Тын Дон») эпопеясының икенче, дүртенче китапларын (1964, 1965), Татар дәүләт академия театры өчен Н.Погодин, А.Островский һәм башка драматургларның пьесаларын татар теленә тәрҗемә итә.

**2 а.б.** *(Алып баручы Гариф Ахунов тәрҗемәсендә Михаил Шолоховның «Тын Дон» әсәреннән өзек укый). (Аудиоязмада күк күкрәгән, яңгыр яуган тавышлар ишетелә).*

«Көнчыгыштан актарылып кара болыт килә. Гөлдер-гөлдер килеп күкрәп куя иде. Болыт тауларының түбәләрен ярып,

күк буйлап ап-ак яшен уты сызылып төште. Җил үләннәрне шыбырдатып көнбатышка таба ия, олы юлдан әчкелтем тузан өереп китерә, көнбагышларның авыраеп аска салынган башларын җиргә кадәр бөгә иде.

Җил Натальяның таралып киткән чәчләрен тузгыта, аның юеш битен киптерә, эшкә кия торган киң итәкле юбкасын ботларына сылый иде.

Ильинична беравык килененә ниндидер хәвефләнү белән, коты алынып карап торды. Ярты күкне иңләп алган кап-кара болыт фонында ул аңа чит-ят булып, куркыныч булып тоелды.

Ашыгып яңгыр килә иде. Яшен алдыннан була торган тынлык озакка бармады. Кыйгачлап төшеп килгән лачын борчулы чырылдады, оясында соңгы мәртәбә йомран сызгырды, куе җил Ильиничнаның битенә ком тузаны китереп бәрде дә улап дала буенча чапты. Карчык авырлык белән генә торып басты. Йөзе аның үлек чырае төсле ак иде:

– Акылыңа кил! Алла сакласын! Кемгә үлем телисең син?! – диде ул, якынлашып килгән зилзилә тавышлары аркылы. Наталья, яшен яктысында кабынып-кабынып киткән һәм асты-өскә килеп иләмсез өерелгән дәһшәтле болытларга акылсыз күзләрен төбәп:

– Җәзала шуны, тәңрем! Җәзала, ходаем! – дип кычкырына иде.

Дала өстендә чатырдап яшен атты. Куркудан йөрәге алынган Ильинична чукынып куйды, хәлсез адымнары белән Наталья янына килеп, аны җилкәсеннән эләктереп алды:

– Тезлән хәзер үк! Ишетәсеңме, Наташка?

Наталья берни күрмәс күзләре белән каенанасына карап алды да ихтыярсыз җиргә тезләнде.

– Тәңредән ярлыкавын сора! – дип, хаким тавыш белән боерды Ильинична. – Теләгеңне кабул күрмәсен. Кемгә үлем теләдең, ә? Балаларыңның газиз аталарына теләдең бит. Ах, гөнаһ, гөнаһ... Чукын! Башыңны җиргә и. Әйт, кабатла: «Тәңрем, гөнаһлы бәндәңне кичер, гөнаһымны йол», – диген.

Наталья чукынып алды да, агарынып киткән иреннәре

белән нидер пышылдап, тешләрен кысып, әллә ничек ипсез генә бер якка авышып төште».

**1 а.б.** Гариф Ахуновның проза әсәрләреннән күбесе русчага тәрҗемә ителә, хикәя һәм повестьлары украин, үзбәк, кыргыз, мари, чуаш, якут һ.б. телләрдә басыла, «Хәзинә» романы казакъча һәм төрекмәнчә тәрҗемәдә нәшер ителә.

Әдәбият өлкәсендәге казанышлары һәм иҗтимагый тормыштагы актив эшчәнлеге өчен Гариф Ахунов 1975 елда Хезмәт Кызыл Байрагы, 1981 елда Халыклар Дуслыгы орденнары белән бүләкләнә, 1972 елда аңа «Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә, ә 1993 елда Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев Указы белән ул «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мәртәбәле исемгә лаек була. Әдип шулай ук 1998 елдан Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы дигән мактаулы исем йөртә. 1973 елда Гариф Ахунов Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

Ул 2000 елның 4 июнендә Казанда вафат була һәм туган ягы Арча зиратына җирләнә.

**2 а.б.** Хөрмәтле кунаклар, Гариф Ахуновка багышланган әдәби кичәбез ахырына якынлашты. Аның иҗаты, әдәби әсәрләре сездә дә кызыксыну уяткандыр дигән теләк белән кичәбезне тәмамлыйбыз. Исән-сау булыгыз! Киләсе очрашуларга кадәр!

*(Кичә тәмам).*

**Файдаланылган чыганаклар:**


1. Ахунов Г. Җуелмас яра // Мәйдан. – 2015. – № 9. – Б. 7–8.
2. Ахунов Г. Тимерханның яшьлеге // Тимерханның күргән-кичергәннәре: докум. повестьлар. – Казан: Татар китабы, 1999. – Б. 4–5.
3. Ахунов Г. Идел кызы: романнан өзек // Гариф Ахунов. Сайланма әсәрләр. – Казан: Хәтер, 2005. – Б. 292–293.
4. Ахунов Г. Яшьлек яме: повестьтан өзек // Гариф Ахунов. Сайланма әсәрләр. – Казан: Хәтер, 2005. – Б. 58.

5. Шолохов М. Тын Дон: Дүрт кит. роман. Кит. 4 / Гариф Ахунов тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – Б. 157–158.
6. Клад: По мотивам романа Гарифа Ахунова: [фильм]. – URL: https://ok.ru/video/985416862409 (дата обращения 30.10.2024).

## ВИКТОРИНА ҮТКӘРҮ ӨЧЕН СОРАУЛАР

*(Түбәндә бирелгән сорауларны кулланып, китап укучылар арасында викторина үткәрергә, кроссворд төзеп чишәргә мөмкин).*

1. Гариф Ахуновның туган җире?
*(Татарстан Республикасының Арча районы Өчиле авылы)*

2. Гариф Ахуновның беренче әсәре ничәнче елда һәм нинди исем белән басылып чыга?
*(1951 елда, «Галләм сорау бирә» хикәясе)*

3. Гариф Ахунов кайсы язучыларның әсәрләрен, пьесаларын тәрҗемә иткән?
*(Шолохов М., Закруткин В., Макаренко А., Тагор Р., Шундик Н., Погодин Н., Островский А.)*

4. Гариф Ахуновның нинди пьесаларын беләсез?
*(«Чулпы җыры», «Утлар яна учакта», «Тынгысыз йөрәк», «Ардуан батыр»)*

5. «Таң атканда уйланам,
Су акканда моңланам.
Таң нурында син йөзәсең,
Утларында мин янам» – әлеге җырның сүзләре Гариф Ахуновның кайсы әсәреннән алынган һәм җырның исеме ничек?
*(«Утлар яна учакта» пьесасыннан, «Гүзәлия җыры»)*

6. Гариф Ахуновның язучылар иҗатын чагылдырган әсәренең исемен әйтегез?
*(«Йолдызлар калка»)*

7. «Әйе, төш күрде Тимерхан абзагыз. Болыннан бара, имеш. Атка атланып бара. Яз, имеш. Күзләрне камаштырырлык кояш болындагы ямь-яшел үләннәргә, аллы-гөлле чәчәкләргә көлтә-көлтә нурын сибә. Тимерхан атланган ат, башын чайкый-чайкый, болын чәчәкләре арасыннан бара, чапмый да, юыртмый да, атлап-атлап кына бара».

Тимерхан атланган атның исеме ничек һәм ул кайсы әсәрдән?

*(Тимеркүк. «Тимерханның күргән-кичергәннәре» исемле әсәреннән)*

8. Гариф Ахуновның «Хәзинә» романының дәвамы нинди исем астында басылып чыга?

*(«Хуҗалар»)*

9. Гариф Ахунов нинди әсәрләре өчен һәм ничәнче елда Габдулла Тукай премиясе белән бүләкләнә?

*(«Чикләвек төше» повесте, «Хәзинә» романы өчен 1973 елда)*

10. Аның кайсы әсәре буенча нинди кинофильм төшерелде?

*(«Хәзинә»)*

11. Язучының әсәрләре кайсы телләргә тәрҗемә ителгән?

*(Рус, украин, үзбәк, казакъ, башкорт, кыргыз, мари, чуаш, якут һ.б.)*

12. Гариф Ахуновның нинди романнарын беләсез?

*(«Идел кызы», «Хәзинә», «Хуҗалар», «Гомер юлы» )*

13. Аның нинди әсәре Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелды?

*(«Чикләвек төше»)*

14. Гариф Ахунов кайсы редакциядә эшләгән?

*(«Казан утлары» журналы редакциясендә)*

15. Гариф Ахунов әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итүчеләрдән кемнәрне беләсез?

*(Рәшит Ахунов, Рөстәм Кутуй, Марсель Зарипов, Булат Хәмидуллин, Василий Харчев)*

16. Гариф Ахуновның кайсы әсәрләре рус теленә тәрҗемә ителгән?

*(«Идел кызы», «Хәзинә», «Тимерханның күргән-кичергәннәре», «Артышлы тау буенда», «Зәңгәр чәчәк – гашыйклар төсе», «Чикләвек төше», «Канатлар кая илтә?»)*

17. «Артышлы тау буенда» әсәре герое Хәсәннең кушаматы?

*(«Ат чебене»)*

18. «Артышлы тау буенда» повестендагы атларның кушаматлары? *(Чикылтык, Давыл, Барабансон)*

19. Солтан белән Нурия нинди спектакльгә баралар? Әлеге геройлар Гариф Ахуновның кайсы әсәреннән?

*(«Зәңгәр шәл» спектакле, «Идел кызы»)*

20. «Хәзинә» романы буенча төшерелгән нәфис фильмда катнашкан артистлардан кемнәрне беләсез?

*(Александр Филиппенко, Марианна Вертинская, Роман Громадский, Шәүкәт Биктимеров, Афанасий Кочетков)*

## ГАРИФ АХУНОВНЫҢ «ХӘЗИНӘ» РОМАНЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ИНТЕРНЕТ-ЧЫГАНАКЛАР ИСЕМЛЕГЕ:

1. Ахунов Г. Хәзинә: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. – 268 б.

2. Ахунов Г. Хәзинә: 2 китаплы роман. – Төзәт. 2 басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 480 б.

3. Биктимеров Ш. «Безгә генә күчеп кил!» // Гариф Ахунов: Хәзинәле гомер. – Казан: Рухият, 2015. – Б. 101.

4. Гайфуллина Ф. Гариф Ахуновның «Хәзинә» романында табигатьне саклау мәсьәләсе // Фән һәм мәктәп=Наука и

школа. – 2014. – № 12. – Б. 13–14.
5. Гайфуллина Ф. Кеше – үзе зур хәзинә // Гариф Ахунов: Хәзинәле гомер. – Казан: Рухият, 2015. – Б. 93–95.
6. Гайфуллина Ф. Кеше – үзе хәзинә: (XI сыйныфта Г.Ахуновның «Хәзинә» романы буенча дәрес-диспут) // Мәгариф. – 2003. – № 5. – Б. 16–17.
7. Гайфуллина Ф. «Хәзинә», «Хуҗалар» романнарында, «Артышлы тау буенда», «Канатлар кая илтә?» повестьларында заман рухын яктырту // Гайфуллина Ф. Гариф Ахунов прозасы (иҗат үсеше). – Казан, 2003. – Б. 32–56.
8. Гайфуллина Ф. Художественное своеобразие романа Гарифа Ахунова «Клад». – Казань: Казан. ун-т, 2003. – 20 с.
9. Ганиева Н. Без дә киногa төшкән идек // Гариф Ахунов: Хәзинәле гомер. – Казан: Рухият, 2015. – Б. 99.
10. Гарифуллина С. Нефтьче образлары – экранда // Гариф Ахунов: Хәзинәле гомер. – Казан: Рухият, 2015. – Б. 96–97.
11. Зарипова З. Тарихка кереп калдык // Гариф Ахунов: Хәзинәле гомер. – Казан: Рухият, 2015. – Б. 98.
12. Заһитова Ч. Гариф Ахуновның «Хәзинә» романыннан өзекләр өйрәнү // Совет мәктәбе. – 1982. – № 5. – Б. 21.
13. Миңнуллина Ә. Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы язылуга 50 ел тулды // Гариф Ахунов: Хәзинәле гомер. – Казан: Рухият, 2015. – Б. 115.
14. Надыршина Л. Гариф Ахунов (1925–2000) // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда: Т. 6: 1960–1980 еллар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – Б. 127–129.
15. Нәҗипова-Зиннәтуллина Ә. Хәзинәләр тапкан әдип // Гариф Ахунов. Сайланма әсәрләр. – Казан: Хәтер, 2005. – Б. 5–16.
16. Хамукова Ж. Чудные были времена // Гариф Ахунов: Хәзинәле гомер. – Казан: Рухият, 2015. – Б. 102–103.
17. Абдюшева А. Ш. Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы (дәрес конспекты) // Международный каталог для учителей, преподавателей и студентов «Конспекты уроков». – URL: https://xn----dtbhtbbrhebfpirq0k.xn--p1ai/liter/10-klass/file/78552-urok (дата обращения: 30.10.2024)

18. Сибгатуллина А. Ф. Гариф Ахуновның «Хәзинә» романында тел-стиль үзенчәлекләре // Мәгариф социаль челтәре. – URL: https://nsportal.ru/shkola/rodnoy-yazyk-i-literatura/library/2017/10/20/garif-ahunovnyn-hzin-romanynda-tel-surtlu (мөрәҗәгать итү датасы: 30.10.2024)

## ГАРИФ АХУНОВ ТУРЫНДА КАЛӘМДӘШЛӘРЕ

Гариф ач-ялангач елларда укыды. Бик яшьли үз көнен үзе күрде. Ләкин ул бер чакта да язмышына зарланмады, тормышның ямен-тәмен таба белде, тапканын кадерләп тотарга өйрәнде. Искиткеч тыйнак, кеше сүзенә һәм гамәленә игътибарлы бу егетебез берзаман күтәрелеп китте. Бик яшьли Язучылар берлегенә кабул ителде. Берсеннән-берсе мавыктыргыч әсәрләр иҗат итте. Берчакта да үзенең гражданлык йөзен югалтмады, татар халкының олы бер улы булып кала белде.

**Аяз Гыйләҗев**

Соңгы ярты гасырлык татар әдәбиятын Гариф Ахуновсыз күз алдына китерү кыен. Язган әсәрләре, китаплары буенча да, әдәби хәрәкәтне оештыруда кылган гамәлләре буенча да. Аны, мөгаен, татар совет әдәбияты классигы дип атау дөрес буладыр. Шушы чор сәяси тормышның, әдәби барышның бөтен позитив һәм негатив яклары чагылыш таба аның иҗат эшчәнлегендә. Бер яктан, Г.Ахунов шул чор идеологиясенең күндәм хезмәтчесе, икенче яктан, татар милләте, татар әдәбияты мәнфәгатьләрен армый-талмый кайгыртучы фидакарь халык улы булды.

**Равил Фәйзуллин**

Гариф Ахунов – гади кеше, самими кеше, ачык кеше. Ул – кешеләрне яратучы җан. Кешеләрнеярату һәркемгә дә кирәкле сыйфат, язучы исә шуннан башка кәгазьгә ике сүз дә төшерә алмый. Чөнки аның төп сурәтләгәне – кеше. Үзең сокланмаган, олылап карамаган нәрсә турында илһамланып язып була-

мы? Юк, мең тапкыр юк. Аның барлык каһарманнары иң әүвәл автор үзе сокланган кешеләр.

**Фоат Галимуллин**

Гариф абыйның холкы, тегендә-монда каранып, моны әйтсәм ни булыр да, тегене дәшми калсам яхшырак булмасмы, дия торган түгел иде. Ул һәрвакыт дөреслекне кычкырып яклый иде. Ә дөреслек, аның өчен, сәләте булган һәр кешенең уңышларын күрү, кимчелекләреннән сак кына арындыру, аны мөмкин кадәр канатландыру, очындыру, дәртләндерү иде. Чөнки үз көченә ышанган, зур эшләр башкарачагына инанып, канатланып иҗат иткән талант иясе генә матур әсәрләр тудыра ала.

**Мәдинә Маликова**

Гариф Ахунов татар әдәбиятында үз урынын күптән раслады. Аның әсәрләре, милли ызаннарны үтеп, бүтән тарафларга, бүтән илләргә, бүтән телләргә барып җитте. Татар халкы хакында, татарның рухи булмышы хакында хак сүз сөйләп, дөнья алдында милләтнең дә, үзенең дә дәрәҗәсен саклады. Эреләнми генә эре сүз сөйләде.

**Мостай Кәрим**

Эшсез йөргән Гариф Ахуновны мин белмим. Хәтта ул, кешеләр белән сөйләшкәндә дә, вакыт-вакыт онытылып китә, эшләнәсе эше турында уйлый, әңгәмәдәшен тыңламый-ишетми башлый иде. Аның кебек тырыш язучылардан мин Габдрахман Әпсәләмов, Аяз Гыйләҗев, Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллинны гына беләм. Ни кызганыч, яшьләребезнең күбесенә алардагы тырышлык җитенкерәми. Гариф абый бәйрәм итәргә ярата иде. Әмма эш хисабына бәйрәм итмәде. Туктаусыз кайнап торган казан иде ул.

**Туфан Миңнуллин**

Болыннарда язын үлән үскән чакта, чәчәкләрне сыйпый-сыйпый язучы Гариф Ахуновның Йөзлебикәсе һәрберебез

